КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 5 июнь г.Казань № 425

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 17 нче карары белән расланган Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан сөтчелек терлекчелеге продуктивлылыгын арттыруга юнәлдерелгән субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 17 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 5 март, 138 нче; 2018 ел, 2 апрель, 200 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан сөтчелек терлекчелеге продуктивлылыгын арттыруга юнәлдерелгән субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «мартта» сүзен «июндә» сүзенә алмаштырырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Реализацияләнгән һәм (яки) үз эшкәртүе өчен алынган югары һәм беренче сортлы сыер сөте өчен алучыга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_r = \sum W_m,$$

монда:

$W_r$ – алучыга бирелә торган субсидия күләме;

$W_m$ – хисап ае өчен реализацияләнгән һәм (яки) үз эшкәртүе өчен алынган югары һәм беренче сортлы сыер сөте өчен алучыга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_m = V_m \times S_m,$$

монда:

$V_m$ – агымдагы хисап аенда алучы тарафыннан реализацияләнгән һәм (яки) үз эшкәртүе өчен алынган югары һәм беренче сортлы сыер сөте күләме;

$S_m$ – хисап ае өчен 1 килограмм реализацияләнгән һәм (яки) үз эшкәртүе өчен алынган югары һәм беренче сортлы сыер сөтенә субсидия ставкасы, шул исәптән:

гыйнвар, февраль, апрель, май өчен – 3,0 сум;

март өчен – 3,325 сум;

июнь өчен - реализацияләнгән һәм (яки) үз эшкәртүе өчен алынган югары, беренче сортлы сыер сөте күләмнәреннән чыгып, Министрлык тарафыннан раслана торган һәм түбәндәге формала буенча билгеләнә торган күләмдә:

$$S_m = \frac{Rr - R_{(\text{январь} \ - \text{май})}}{V_{(\text{июнь})}} \ ,$$

монда:

Rr – агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында реализацияләнгән һәм (яки) үз эшкәртүе өчен алынган югары һәм беренче сортлы сыер сөтенә каралган һәм алучыларга бирелә торган акча күләме;

$R_{(\text{гыйнвар} - \text{май})}$ – агымдагы финанс елының гыйнвар – май өчен реализацияләнгән һәм (яки) үз эшкәртүе өчен алынган югары һәм беренче сортлы сыер сөте өчен алучыларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән акча күләме;

$V(_{\text{июнь}})$ – агымдагы финанс елының июнендә реализацияләнгән һәм (яки) үз эшкәртүе өчен алынган югары, беренче сортлы сыер сөте күләме.»;

8 пунктның сигезенче һәм тугызынчы абзацларында «мартта» сүзен «июндә» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин